КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 Октябрь г.Казань № 822

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә «Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы профильле дәүләт табигый тыюлыгын булдыру турында

«Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, табигать комплексларын саклау, шул исәптән өске сфагнум сазлыгы комплексын саклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә 10,3 гектар мәйданлы «Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы профильле дәүләт табигый тыюлыгын булдыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

«Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы чикләре урнашу урынының график тасвирламасын.

3. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасының махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

«Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы турында нигезләмә һәм аның чикләре хакындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен

документларны «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына җибәрергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 11 октябрь, 822 нче
карары белән расланды

«Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплексلы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәне;

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы (алга таба – тыюлык) төбәк әһәмиятендәге аеруча саклanучы табигать территориясе булып тора, ул үсемлекләрнең сирәк очрый торган һәм саклана торган сазлык төрләре комплексы үсү урыны булган өске сфагнум сазлыгы комплексын саклау максатыннан булдырылган.

Тыюлык Апас муниципаль районы территориясендә урнашкан һәм аның гомуми мәйданы 10,3 гектар тәшкил итә.

1.2. Тыюлык Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

Тыюлыкның чикләре җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнә.

1.3. Тыюлык Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) карамагында.

1.4. Тыюлык чикләре һәм махсус саклау режимы үзенчәлекләре территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман корылышы эшчәнлеген башкарганда һәм җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

II. Тыюлыкның махсус саклау режимы

2.1. Тыюлык территориясендә табигать комплексларына тискәре (зарарлы) йогынты ясый торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклардан тыш, биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү;

әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы өченче абзацында каралган очраклардан тыш, капиталь төзелеш объектларын, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, шулай ук бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып бару өчен җир кишәрлекләре бирү һәм барлыкка китерү;

автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

агып җыела торган суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

әгәр тыюблыкның табигать комплексларына зыян китерсәләр, гидрологик режимны үзгәртү, су ресурсларын эксплуатацияләү;

тыюлык эшчәнлегенә бәйле булмаган гидромелиорация һәм ирригация эшләрен башкару;

файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары

кишәрлекләрен геологик өйрәнүне һәм аларның яраклылыгын бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнүне үткәрү (әлеге эшчәнлекне тыюлык булдырылганга кадәр бирелгән лицензияләр буенча җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары нигезендә гамәлгә ашырудан тыш);

агачларны, куакларны кисү һәм (яисә) үсемлекләр капламын бозу (урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларын уздыру очракларыннан тыш), урманнарны саклау, яклау һәм яңадан җитештерү, табигать комплексларын һәм тыюлык объектларын саклау һәм торгызу максатларында авыл хуҗалыгы чаралары, гражданнар куркынычсызлыгын тәэмин итү, линия объектларын эксплуатацияләү куркынычсызлыгы буенча, шул исәптән аларны саклау зоналары киңлеген саклау буенча, линия объектларына техник хезмәт күрсәтү кысаларында реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау буенча, төзелешләре әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктының икенче абзацы нигезендә рөхсәт ителә торган объектлар төзүгә бәйле очраклардан тыш;

барлык төрләрдәге калдыкларны урнаштыру, туфракларны, грунтларны, җир өсте һәм җир асты суларын пычрату;

материалларны, грунтларны, карны өеп кую;

учаклар кабызу, корыган яфраклар һәм үләннәр яндыру;

туфрак катламын бозу, җир эшләре башкару (урман янгыннарына каршы тору чараларын, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге чараларны үтәгәндә, линия объектларын эксплуатацияләгәндә, фәнни тикшеренүләр, шул исәптән табигать объектларын һәм тыюлык комплексларын өйрәнүгә һәм торгызуга юнәлдерелгән, мәдәни мирас объектларын өйрәнү һәм саклап калуга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләрне үткәргәндә туфрак катламын бозу, җир эшләре башкару очракларыннан тыш, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектлар төзүгә бәйле очраклардан тыш);

яшәү тирәлегеннән алып, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану, шулай ук хайваннар дөньясы объектларына зыян китерү (хайваннар дөньясы объектларын фәнни максатларда, һәвәскәр һәм спорт аучылыгы максатларында файдаланудан, аларның санын җайга салу, шулай ук сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларының популяцияләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш);

хайваннарның ояларын, өннәрен һәм башка яшәү урыннарын бетерү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр кылу;

киртәләргә, аншлагларга, шлагбаумнарга, стендларга, чик баганаларына, күрсәткечләргә һәм башка мәгълүмат билгеләренә, эшләнгән экологик сукмакларга, төзелмәләргә һәм корылмаларга зыян салу, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

механик транспорт чаралары, юлсыз мототранспорт чаралары йөрү һәм тукталыш, барлык йөзү чаралары (шул исәптән аз үлчәмле үзйөрешле суднолар) йөрү һәм тукталыш, механик транспорт чаралары, юлсыз мототранспорт чаралары, махсус техника йөрү һәм тукталыштан тыш:

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башка дәүләт органнарының һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характер йөрткән башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

ау хуҗалыгы килешүләре нигезендә хайваннар дөньясын файдаланучы ау кулланучылары;

тыюлык территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең җир хуҗалары, җирдән файдаланучылары, милекчеләре;

табигать һәйкәлендә табигать комплексларының экологик тигезлеген боза торган, табигать һәйкәле территориясенең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының саклана торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

2.2. Тыюлык территориясендә, Дәүләт комитеты белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

тыюлык булдыру максатларына ирешүгә һәм аның төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзү һәм реконструкцияләү; яңа төзелмәләр, корылмалар, капиталь төзелеш объектлары, гидротехник корылмалар, инженерлык һәм техник коммуникацияләр, линия объектлары төзү (тыюлыкның чикләреннән чыгып аларны урнаштыру вариантлары булмаган очракта); элегрәк төзелгән капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линия объектларын һәм инженерлык-техник коммуникацияләрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендә куллану, шулай ук әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре бирү һәм барлыкка китерү;

җирләрне яки мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү;

җир кишәрлекләрен һәм су объектларын экологик реабилитацияләү, җир кишәрлекләрен рекультивацияләү;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрне, шулай ук аларның яшәү тирәлеге мохитен саклау чараларын гамәлгә ашыру;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрнең яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге буларак аеруча кыйммәтле булган кишәрлекләрдә су үләнчел үсемлекләре әзерләү һәм чабу;

урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрү, урманнарны яклау буенча профилактик чаралар, санитария-савыктыру чаралары, шул исәптән урманнарны караганда урман утыртмаларын кисү, һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү чаралары (1 апрельдән 31 июльгә кадәр ояда утыру һәм балалар чыгару чорында агачлар кисүдән тыш);

әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзегәндә агачларны, куакларны кисү һәм (яки) үсемлек капламын бозу;

биотөрлелекне, табигать объектларын һәм комплексларны өйрәнүгә һәм торгызуга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр үткәрү, шулай ук археологик мирас объектларын ачыклау, өйрәнү һәм саклау максаты белән археологик кыр эшләрен башкару, шул исәптән дайвингны гамәлгә ашыру юлы белән;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

печән чабу;

мал-туар көтү;

төбәк геологиясен өйрәнү.

2.3. Углеводород чималын чыгару буенча гамәлдәге лицензияләрне тормышка ашыру кысаларында, Дәүләт комитеты белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

геологик разведка һәм сейсмик разведка эшләрен үткәрү;

нефть һәм газ ятмаларын, табигый битумнарны проектлаштыру, чыгару һәм төзекләндерү эшләрен үткәрү;

нефть инфраструктурасы объектларын төзү эшләрен үткәрү;

нефть чыгару объектларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү эшләрен үткәрү.

2.4. Тыюлык территориясендә хуҗалык эшчәнлеге бу Нигезләмәгә һәм җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә расланган транспорт магистральләрен, торба үткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау таләпләренә таянып гамәлгә ашырыла.

## III. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре

3.1. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторынраслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә тыюлык чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төрләре, әгәр алар әлеге Нигезләмәнең II бүлегендәге таләпләренә каршы килмәсә, рөхсәт ителә:

төп эшчәнлек төрләре:

печән чабу (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.19*);

авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (1.20*);

фәнни тикшеренүләр үткәрү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (3.9.2*);

табигатьне танып белү туризмы (Дәүләт комитеты белән килештереп) (5.2*);

табигать территорияләрен саклау (9.1*);

тарихи-мәдәни эшчәнлек (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.3*);

су объектларыннан гомуми файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.1*);

эшчәнлекнең ярдәмче төрләре:

---

*Код билгеләнеше Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча.

«коммуналь хезмәтләр күрсәтү (Дәүләт комитеты белән килештереп) (3.1.1*);

файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару (тыюлык булдырылганчы бирелгән җир асты байлыкларын файдалану лицензияләре буенча гына) (6.1*);

элемтә (Дәүләт комитеты белән килештереп) (6.8*);

торба үткәргеч транспорт (Дәүләт комитеты белән килештереп) (7.5*);

су объектларыннан махсус файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.2*);

гидротехник корылмалар (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.3*).

## IV. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары

4.1. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары:

биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның иң чик биеклеге – бер кат;

җир кишәрлеге чикләрендә йорт салу проценты – иң күбе 50 процент.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 11 октябрь, 822 нче карары белән расланды

«Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы чикләре урнашу урынының график тасвирламасы

1 бүлек

| Объект турында мәгълүматлар | | |
|---|---|---|
| Т/с | Объектның тасвирнамәләре | Тасвирнамәләрнең тасвирламасы |
| 1 | Объектның урнашу урыны | Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Югары Ындырчы авыл җирлеге |
| 2 | Объектның мәйданы +/- мәйданны билгеләү төгәлсезлеге зурлыгы (Р +/- Дельта Р) | 103 323 кв.м +/- 5 625 кв.м |
| 3 | Объектның башка тасвирнамәләре | - |

2 бүлек

| Объект чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы: Халыкара координатлар системасы – 16 | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, м | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билгесенең тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чик өлешенең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, м | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билгесенең тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 нче өлеш | | | | | |
| 1 | 423843.71 | 1261513.84 | Картометрик | 5.00 | - |
| 2 | 423855.61 | 1261553.94 | Картометрик | 5.00 | - |
| 3 | 423862.91 | 1261611.14 | Картометрик | 5.00 | - |
| 4 | 423860.49 | 1261632.71 | Картометрик | 5.00 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | 423854.66 | 1261663.13 | Картометрик | 5.00 | - |
| 6 | 423841.12 | 1261683.96 | Картометрик | 5.00 | - |
| 7 | 423823.17 | 1261699.04 | Картометрик | 5.00 | - |
| 8 | 423791.83 | 1261718.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 9 | 423771.83 | 1261725.22 | Картометрик | 5.00 | - |
| 10 | 423749.38 | 1261721.28 | Картометрик | 5.00 | - |
| 11 | 423737.20 | 1261713.93 | Картометрик | 5.00 | - |
| 12 | 423726.85 | 1261701.27 | Картометрик | 5.00 | - |
| 13 | 423718.37 | 1261658.74 | Картометрик | 5.00 | - |
| 14 | 423718.21 | 1261658.42 | Картометрик | 5.00 | - |
| 15 | 423713.97 | 1261583.23 | Картометрик | 5.00 | - |
| 16 | 423720.23 | 1261560.73 | Картометрик | 5.00 | - |
| 17 | 423730.39 | 1261540.43 | Картометрик | 5.00 | - |
| 18 | 423742.39 | 1261524.64 | Картометрик | 5.00 | - |
| 19 | 423762.12 | 1261512.27 | Картометрик | 5.00 | - |
| 20 | 423783.73 | 1261500.92 | Картометрик | 5.00 | - |
| 21 | 423802.51 | 1261498.85 | Картометрик | 5.00 | - |
| 22 | 423823.80 | 1261499.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 23 | 423837.10 | 1261506.17 | Картометрик | 5.00 | - |
| 1 | 423843.71 | 1261513.84 | Картометрик | 5.00 | - |
| 2 нче өлеш | | | | | |
| 24 | 423693.32 | 1261780.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 25 | 423701.30 | 1261783.72 | Картометрик | 5.00 | - |
| 26 | 423705.56 | 1261788.74 | Картометрик | 5.00 | - |
| 27 | 423710.30 | 1261799.54 | Картометрик | 5.00 | - |
| 28 | 423716.35 | 1261824.17 | Картометрик | 5.00 | - |
| 29 | 423722.66 | 1261863.24 | Картометрик | 5.00 | - |
| 30 | 423722.94 | 1261872.15 | Картометрик | 5.00 | - |
| 31 | 423698.18 | 1261855.60 | Картометрик | 5.00 | - |
| 32 | 423674.27 | 1261843.85 | Картометрик | 5.00 | - |
| 33 | 423654.32 | 1261838.24 | Картометрик | 5.00 | - |
| 34 | 423642.60 | 1261837.89 | Картометрик | 5.00 | - |
| 35 | 423617.07 | 1261843.27 | Картометрик | 5.00 | - |
| 36 | 423586.51 | 1261855.19 | Картометрик | 5.00 | - |
| 37 | 423555.65 | 1261863.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 38 | 423522.21 | 1261868.49 | Картометрик | 5.00 | - |
| 39 | 423503.31 | 1261864.51 | Картометрик | 5.00 | - |
| 40 | 423487.83 | 1261852.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 41 | 423482.32 | 1261844.13 | Картометрик | 5.00 | - |
| 42 | 423479.08 | 1261835.10 | Картометрик | 5.00 | - |
| 43 | 423476.93 | 1261825.04 | Картометрик | 5.00 | - |
| 44 | 423479.28 | 1261812.54 | Картометрик | 5.00 | - |
| 45 | 423494.89 | 1261792.01 | Картометрик | 5.00 | - |
| 46 | 423522.31 | 1261760.39 | Картометрик | 5.00 | - |
| 47 | 423538.55 | 1261747.97 | Картометрик | 5.00 | - |
| 48 | 423550.59 | 1261744.43 | Картометрик | 5.00 | - |
| 49 | 423567.83 | 1261745.07 | Картометрик | 5.00 | - |
| 50 | 423623.15 | 1261762.28 | Картометрик | 5.00 | - |
| 24 | 423693.32 | 1261780.45 | Картометрик | 5.00 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 нче өлеш | | | | | |
| 51 | 423125.25 | 1261680.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 52 | 423131.00 | 1261685.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 53 | 423135.25 | 1261690.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 54 | 423136.50 | 1261693.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 55 | 423140.50 | 1261713.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 56 | 423142.00 | 1261724.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 57 | 423140.75 | 1261727.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 58 | 423138.25 | 1261729.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 59 | 423133.75 | 1261729.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 60 | 423127.50 | 1261726.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 61 | 423121.75 | 1261722.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 62 | 423114.50 | 1261715.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 63 | 423109.25 | 1261713.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 64 | 423097.25 | 1261712.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 65 | 423085.75 | 1261712.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 66 | 423073.75 | 1261716.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 67 | 423059.25 | 1261717.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 68 | 423048.25 | 1261717.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 69 | 423045.75 | 1261716.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 70 | 423040.75 | 1261713.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 71 | 423036.50 | 1261707.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 72 | 423033.50 | 1261700.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 73 | 423031.25 | 1261684.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 74 | 423030.75 | 1261675.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 75 | 423033.50 | 1261673.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 76 | 423038.00 | 1261670.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 77 | 423043.75 | 1261668.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 78 | 423052.00 | 1261666.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 79 | 423060.75 | 1261663.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 80 | 423066.50 | 1261663.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 81 | 423076.00 | 1261668.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 82 | 423085.50 | 1261670.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 83 | 423096.25 | 1261672.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 84 | 423115.75 | 1261677.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 51 | 423125.25 | 1261680.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 4 нче өлеш | | | | | |
| 85 | 423015.75 | 1261548.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 86 | 423019.50 | 1261553.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 87 | 423026.75 | 1261557.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 88 | 423032.00 | 1261562.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 89 | 423035.00 | 1261566.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 90 | 423035.50 | 1261571.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 91 | 423034.25 | 1261578.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 92 | 423031.50 | 1261583.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 93 | 423026.25 | 1261587.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 94 | 423012.25 | 1261592.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 95 | 423004.50 | 1261594.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 96 | 422999.50 | 1261593.45 | Картометрик | 5.00 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 97 | 422994.50 | 1261589.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 98 | 422991.50 | 1261585.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 99 | 422987.50 | 1261580.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 100 | 422980.50 | 1261566.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 101 | 422977.00 | 1261555.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 102 | 422977.00 | 1261552.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 103 | 422979.50 | 1261550.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 104 | 422985.75 | 1261549.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 105 | 423005.00 | 1261547.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 106 | 423011.25 | 1261547.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 85 | 423015.75 | 1261548.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 5 нче өлеш | | | | | |
| 107 | 422962.68 | 1261414.42 | Картометрик | 5.00 | - |
| 108 | 422966.07 | 1261423.00 | Картометрик | 5.00 | - |
| 109 | 422969.22 | 1261451.79 | Картометрик | 5.00 | - |
| 110 | 422966.59 | 1261475.65 | Картометрик | 5.00 | - |
| 111 | 422966.58 | 1261475.65 | Картометрик | 5.00 | - |
| 112 | 422959.95 | 1261485.93 | Картометрик | 5.00 | - |
| 113 | 422942.27 | 1261497.90 | Картометрик | 5.00 | - |
| 114 | 422933.80 | 1261501.29 | Картометрик | 5.00 | - |
| 115 | 422915.64 | 1261503.65 | Картометрик | 5.00 | - |
| 116 | 422897.67 | 1261500.76 | Картометрик | 5.00 | - |
| 117 | 422887.08 | 1261494.12 | Картометрик | 5.00 | - |
| 118 | 422876.17 | 1261488.50 | Картометрик | 5.00 | - |
| 119 | 422870.04 | 1261482.92 | Картометрик | 5.00 | - |
| 120 | 422862.17 | 1261479.94 | Картометрик | 5.00 | - |
| 121 | 422856.59 | 1261478.47 | Картометрик | 5.00 | - |
| 122 | 422853.37 | 1261474.29 | Картометрик | 5.00 | - |
| 123 | 422850.18 | 1261465.85 | Картометрик | 5.00 | - |
| 124 | 422848.15 | 1261452.79 | Картометрик | 5.00 | - |
| 125 | 422849.59 | 1261436.57 | Картометрик | 5.00 | - |
| 126 | 422854.33 | 1261424.35 | Картометрик | 5.00 | - |
| 127 | 422858.20 | 1261417.52 | Картометрик | 5.00 | - |
| 128 | 422871.24 | 1261407.67 | Картометрик | 5.00 | - |
| 129 | 422891.68 | 1261399.49 | Картометрик | 5.00 | - |
| 130 | 422910.11 | 1261398.36 | Картометрик | 5.00 | - |
| 131 | 422932.82 | 1261403.03 | Картометрик | 5.00 | - |
| 132 | 422956.77 | 1261410.41 | Картометрик | 5.00 | - |
| 107 | 422962.68 | 1261414.42 | Картометрик | 5.00 | - |
| 6 нчы өлеш | | | | | |
| 133 | 423119.75 | 1261164.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 134 | 423147.50 | 1261170.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 135 | 423144.50 | 1261203.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 136 | 423126.00 | 1261235.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 137 | 423075.75 | 1261288.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 138 | 423062.25 | 1261300.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 139 | 423025.25 | 1261341.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 140 | 422976.50 | 1261367.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 141 | 422957.02 | 1261363.14 | Картометрик | 5.00 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 142 | 422953.44 | 1261361.29 | Картометрик | 5.00 | - |
| 143 | 422941.16 | 1261336.50 | Картометрик | 5.00 | - |
| 144 | 422920.52 | 1261287.53 | Картометрик | 5.00 | - |
| 145 | 422910.36 | 1261255.99 | Картометрик | 5.00 | - |
| 146 | 422907.56 | 1261232.55 | Картометрик | 5.00 | - |
| 147 | 422924.87 | 1261217.82 | Картометрик | 5.00 | - |
| 148 | 422960.23 | 1261200.71 | Картометрик | 5.00 | - |
| 149 | 422961.50 | 1261200.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 150 | 422961.50 | 1261200.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 151 | 422978.75 | 1261197.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 152 | 423000.00 | 1261207.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 153 | 423013.50 | 1261206.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 154 | 423044.25 | 1261194.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 155 | 423078.25 | 1261176.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 133 | 423119.75 | 1261164.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 7 нче өлеш | | | | | |
| 156 | 423058.25 | 1261100.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 157 | 423061.00 | 1261120.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 158 | 423060.00 | 1261143.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 159 | 423049.25 | 1261167.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 160 | 423039.00 | 1261176.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 161 | 423035.50 | 1261181.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 162 | 423025.00 | 1261195.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 163 | 423018.75 | 1261198.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 164 | 423010.50 | 1261201.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 165 | 422999.75 | 1261196.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 166 | 422992.75 | 1261193.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 167 | 422984.75 | 1261186.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 168 | 422983.75 | 1261178.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 169 | 422984.50 | 1261164.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 170 | 422978.50 | 1261146.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 171 | 422972.50 | 1261131.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 172 | 422968.50 | 1261118.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 173 | 422969.25 | 1261106.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 174 | 422978.75 | 1261104.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 175 | 422984.50 | 1261101.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 176 | 422989.75 | 1261093.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 177 | 423003.50 | 1261090.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 178 | 423021.00 | 1261085.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 179 | 423030.50 | 1261085.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 180 | 423039.50 | 1261088.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 156 | 423058.25 | 1261100.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 8 нче өлеш | | | | | |
| 181 | 423229.50 | 1261059.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 182 | 423229.25 | 1261072.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 183 | 423234.00 | 1261078.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 184 | 423236.50 | 1261087.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 185 | 423231.25 | 1261112.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 186 | 423214.50 | 1261131.20 | Картометрик | 5.00 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 187 | 423196.50 | 1261142.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 188 | 423184.50 | 1261145.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 189 | 423176.25 | 1261144.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 190 | 423166.75 | 1261142.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 191 | 423166.25 | 1261128.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 192 | 423168.50 | 1261118.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 193 | 423173.75 | 1261108.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 194 | 423178.50 | 1261089.70 | Картометрик | 5.00 | - |
| 195 | 423180.50 | 1261078.95 | Картометрик | 5.00 | - |
| 196 | 423188.50 | 1261070.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 197 | 423197.50 | 1261065.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 198 | 423206.25 | 1261065.45 | Картометрик | 5.00 | - |
| 199 | 423223.00 | 1261058.20 | Картометрик | 5.00 | - |
| 181 | 423229.50 | 1261059.20 | Картометрик | 5.00 | - |


3 бүлек

| Объектның үзгәртелгән (тәгаенләнгән) чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы: Халыкара координатлар системасы – 16 | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, м | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билгесенең тасвирлама-сы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| - | - | - | - | - | - |

4 бүлек

# «Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы чикләре планы

Объект чикләренең күзәтү схемасы




Масштабы 1 : 25 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

– объект чиге


– муниципаль район чиге

– авыл җирлеге чиге.

4 бүлек

## «Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы чикләре планы

1 нчы бит




Масштабы 1 : 5 000


Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

| | |
|---|---|
| • 1 | – чикләрнең характерлы ноктасы билгесе |
| | – объект чиге |
| | – җир кишәрлеге чиге |
| **16:08:080404** | – кадастр кварталы номеры |
| :54 | – җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| (16:08:000000:225) | – бердәм җирдән файдалануның кадастр номеры |
| (7) | – күпконтурлы җир кишәрлегенең контур номеры. |

4 бүлек

## «Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы чикләре планы

2 нчы бит




Масштабы 1 : 2 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

| | |
|---|---|
| • 51 | – объект чикләренең характерлы ноктасы билгесе |
| (кызыл сызык) | – объект чиге |
| (сары турыпочмак) | – җир кишәрлеге чиге |
| **16:08:080404** | – кадастр кварталы номеры |
| :75 | – җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| (16:08:000000:106) | – бердәм җирдән файдалануның кадастр номеры |
| (7) | – күпконтурлы җир кишәрлегенең контур номеры. |

4 бүлек

# «Өске сфагнум сазлыгы» төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге табигый дәүләт тыюлыгы чикләре планы

3 нче бит




Масштабы 1 : 2 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

| | |
|---|---|
| • 133 | – чикләрнең характерлы ноктасы билгесе |
| | – объект чиге |
| | – җир кишәрлеге чиге |
| **16:08:080404** | – кадастр кварталы номеры |
| :75 | – җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| (16:08:000000:106) | – бердәм җирдән файдалануның кадастр номеры |
| (7) | – күпконтурлы җир кишәрлегенең контур номеры. |